ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.12.2020 ел Баулы шәһәре №251

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 112 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләренә 1нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 октябрендәге 1747 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 112 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге өстәмәләр кертергә:

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләрендә (муниципаль программага 1нче кушымта):

а) пунктчасында 15нче пунктның «әлеге Кагыйдәләргә» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы яшьләр эшләре  буенча бүлек» МКУга шәхси « мөрәҗәгать иткәндә) » сүзләрен өстәргә;

18нче пунктның икенче абзацында «язмача» сүзләрен «кәгазьдә яисә электрон рәвештә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша» сүзләренә алмаштырырга;

33нче пунктның беренче абзацына түбәндәге җөмлә өстәргә:

«Социаль түләү алуга хокук турында бирелгән таныклыкны алыштыру турында гариза «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре буенча бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә кәгазьдә яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша электрон формада тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гузаиров